# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Ювас авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

07 апрель 2024 е. №4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Олы Битаман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Олы Битаман авыл җирлеге Советының 2019 елның 23 октябрендәге 150 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Олы Битаман авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә» нигезендә, «2024 елдаТатарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Ювас торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 1000 (Бер мең) сум күләмендә үз-үзенә салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

1) вак таш сатып алу
2) янгынга каршы гидрант сатып алу һәм урнаштыру
3) урам яктырту җайланмасы
4) чүплекне бетерү

“РИЗА” “КАРШЫ” “ мәсьәләсе буенча 2023 елның 11 декабрендәге 1 нче номерлы гражданнар җыены карарына эш төрләренең исемнәре өлешендә:

- торак пункт эчендәге җирле әһәмияткә ия булган гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын ремонтлау һәм җайлаштыру (вак таш сатып алу)
- Янгынга каршы беренчел чаралар (янгынга каршы гидрант сатып алу һәм урнаштыру)
- урамнарны яктырту (урам яктырту җайланмасы урнаштыру)
- каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын җайлаштыру, каты коммувналь калдыклар җыю өчен контейнерлар булдыру һәм тиешсез урыннардагы чүплекләрне юкка чыгару (чүплекне бетерү) редакциясендә үзгәрешләр кертергә

“РИЗА” “КАРШЫ”

Мәсьәләсе буенча уздырылган гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Гражданнар җыены исемлегенә сайлау хокукы булган 82 (Сиксән ике) кеше кертелде, тавыш бирүдә 58 (Илле сигез) катншты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча: “Риза”, дип 58 (Илле сигез) кеше, “Каршы”. дип 0 (Ноль) кеше тавыш бирде.

Бу нигездә, гражданнар җыены:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Ювас торак пунктында узган гражданнар җыенын таныrга, җыен нәтиҗәләрен гамәлдә дип санарга.

2024 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Ювас авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими рәвештә аваыл территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә.

Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) вак таш сатып алу

2) янгынга каршы гидрант сатып алу һәм урнаштыру

3) урам яктырту җайланмасы

4) чүплекне бетерү

эш төрләренең исемнәре өлешендә:

- торак пункт эчендәге җирле әһәмияткә ия булган гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын ремонтлау һәм җайлаштыру (вак таш сатып алу)

- Янгынга каршы беренчел чаралар (янгынга каршы гидрант сатып алу һәм урнаштыру)

- урамнарны яктырту (урам яктырту җайланмасы урнаштыру)

- каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын җайлаштыру, каты коммувналь калдыклар җыю өчен контейнерлар булдыру һәм тиешсез урыннардагы чүплекләрне юкка чыгару (чүплекне бетерү)

“РИЗА” “КАРШЫ” кабул ителде дип санарга.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм республиканың рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә

Җыен рәисе Ф.Ю.Закиров